Г.Тукай ис. Меслим урта гомуми белем биру мектебе

# Тукай ялкыны

“ Туган телне сөючеләр” пресс-центры Октябрь, 2023 нче ел №1





Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов педагогларны һәм педагогик хезмәт ветераннарын һөнәри бәйрәмнәре белән котлады. Телеграмма республика җитәкчесе сайтында чыкты.«Укытучының эше тирән рухи эчтәлек белән тулган, ул эшкә бирелгәнлекне, көч-куәт, зирәклек, күркәм сабырлык һәм кешеләрне яратуны таләп итә. Укытучы — һөнәргә караганда күбрәк, бу сәләт!» — диде Миңнеханов.Аның сүзләренчә, 2023 елны Россиядә Педагоглар һәм остазлар елы дип игълан итү кеше тормышында педагогның ролен һәм аларның аерым статусын тану булды.Татарстан Рәисе билгеләп үткәнчә, мәгариф системасын камилләштерү дәүләт сәясәтенең өстенлеге булып тора, чөнки нәкъ менә педагоглар милләтнең рухи нигезен һәм киләчәк идеалын формалаштыра.«Татарстанның педагогика мәктәбе Россиядә бәхәссез абруйга ия һәм монда сезнең һәрберегезнең өлеше зур! Данлыклы традицияләр, Татарстан мәгарифенең методик базасын формалаштыруда педагогик хезмәт ветераннары аерым роль уйный, аларның күбесе бүгенге көнгә кадәр яшь буын укытучыларга остаз булып тора», — диде республика җитәкчесе.Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, Укытучы көне һәр педагогка һәм остазга безнең үсешкә йогынты ясаган, һөнәр сайларга ярдәм иткән, яхшы һәм кыю, намуслы һәм җаваплы булырга өйрәткән, үзен белем бирүгә, ә димәк, җәмгыятькә хезмәт итүгә багышлаучыларга рәхмәт белдерү өчен тагын бер мөмкинлек булып тора.

«Укытучы илнең киләчәген төзүдә турыдан-туры катнаша, ата-аналар балаларына укытучыларга рәхмәтле булу, ә укытучылар ата-аналарга хөрмәт һәм мәхәббәт турында күбрәк сөйләсен өчен укытучы хезмәтенең иҗтимагый әһәмиятен күтәрү мөһим», — диде Россия Президенты Владимир Путин 2023 елда Федераль Җыенга юлламасында.

Тулырак: https://alabuganury.ru/news/v-respublike/rostam-minnexanov-pedagoglarny-ukytucylar-kone-belan-kotlady

Хөрмәтле укытучылар, мәгариф оешмалары хезмәткәрләре, педагогик хезмәт ветераннары!

Сезне чын мәгънәсендә бөтенхалык бәйрәменә әйләнгән Укытучылар көне белән ихлас күңелдән котлыйм.Барлык һөнәрләр дә кирәкле, әмма аларның берсе бигрәк тә җаваплы, мактаулы, игелекле һәм хөрмәткә лаеклы. Бу – Укытучы. Көн саен без сабыйларыбызны җитәкләп мәктәпкә юл тотабыз, иң кадерле байлыгыбызны нәкъ менә аңа ышанып тапшырабыз.Укытучы – бик мөһим һөнәр иясе ул! Теләсә кайсы ата-анадан баласын укытуның төп элементы нәрсә дип сорасаң, ул: “Яхшы педагоглар”, - дип җавап бирәчәк.Бары тик бала күңелен аңлый белүче генә чын укытучы була ала. Күбегез өчен мәктәп - ул эш урыны гына түгел, ә икенче өе кебек. Бу һөнәрне башкалар белән дә чагыштыру да дөрес булмас, чөнки сезнең кулда – буыннар язмышы. Үзегезнең фидакарьлегегез, армый-талмый хезмәт итүегез һәм даими иҗади эзләнүегез белән сез киләчәктәге казанышларыбызның һәм иртәгәге көннең нигезләрен саласыз.Кайда эшләвебезгә, язмышның безне Җир шарының кайсы почмакларында йөртүенә һәм нинди яшькә җитүебезгә карамастан, яраткан укытучыбызның һәрвакыт йөрәк түрендә булуы да юкка түгел. Нәкъ менә ул кушләребезнең тормышында зур роль уйнады, булачак һөнәребезне сайларга ярдәм итте һәм безнең сәләтебезне табып, киләчәккә юл күрсәтте.Кадерле укытучыларыбыз, педагогик хезмәт ветераннары! Күңелегезнең мәңге яшьлеге, сүзләрегезнең зирәклеге, тәҗрибәгезнең бәһасезлеге алдында баш иябез. Белемегезне яшь педагоглар белән уртаклашуыгыз өчен зур рәхмәт. Сез алар өчен һөнәргә тугрылык үрнәге булып торасыз.Хөрмәтле педагоглар, сезгә һөнәри осталыгыгыз, сабырлыгыгыз, иҗат рухыгыз, вакыт белән бергә атлавыгыз, балаларның шатлыкларын һәм кичерешләрен аңлый белүегез, укучыларыгызга булган ихлас мәхәббәтегез өчен рәхмәт. Һәр яңа көн сезгә яңа иҗат уңышлары һәм намуслы хезмәтегездән канәгатьлек алып килсен!

Министр Илсур Һадиуллин

## Мәктәп яңалыклары...

Казан шәһәрендә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының 90 еллыгы уңаеннан мәктәп һәм гаилә театрларының I республика фестивале уздырылды. 17 һәм 20 октябрь көннәрендә мәртәбәле жюри коллективларның 100 дән артык чыгышын карады, аларга бәя бирде. 20 октябрь көнне мәктәбебездә эшләп килүче "Асылташ" балалар театрының кечкенә артистлары җитәкчеләре Синара Яббарова белән берлектә Р.Фәизовның "Саодака" пьесасы буенча куелган спектаклен жюри хөкеменә тәкъдим иттеләр. Уңышлы чыгыш ясап, 2 ноябрьдә узачак гала-концертка чакыру алдылар. Җиңүчеләрне Тинчурин театры шефлыкка да алачак әле. Котлыйбыз сезне!



14 нче октябрь көнне безнең мәктәптә "Татарча диктант-2023” Бөтендөнья белем тикшерү акциясе узды. "Татарча диктант"ның максаты – татар теленә кызыксыну тәрбияләү, әдәби телдә грамоталы сөйләм һәм язу күнекмәләрен үстерү, орфографик һәм грамматик хаталарсыз язарга теләк булдыру.



13 октябрьдә районда үткәрелә торган “Әдәбият һәм сәнгать көннәре” кысаларында Г.Тукай ис. Меслим урта гомуми белем биру мәктәбе якташ язучыларны кабул итте. Халык язучысы Фоат Садриев, шагыйрә Шәмсия Җиһангирова, язучы Ләбиб Леронны укучылар туган як турында шигырьләр, милли биюләр белән каршы алдылар. "Шагыйрьгә ун сорау" кызыклы проекты кунаклар һәм укучылар тарафыннан да бик теләп кабул ителде.

**«Укытучым - иң кадерле кешем»**

**(« Укытучылар көне» н үткәрү өчен концерт программасы сценариесе)**

**1аб. Хөрмәтле укытучы апа - абыйлар !**

**2аб. Без - барлык мәктәп укучылары, сезне профессиональ бәйрәмегез белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Сезгә исәнлек-саулык, озын гомер, җан тынычлыгы телибез. Изге эшләрегез безнең өчен, балалар өчен. Шул эшләр башкарган хезмәтегездә иминлек телибез сезгә.**

**1 аб. Укытучы – изге бер сүз ул. Һәр кеше моның мәгънәсенә төшенә. Укытучы бөтен көчен биреп балаларга аң - белем, тәрбия бирергә тырыша.**

**2 аб. Укытучы һөнәре җир йөзендә иң изге һөнәрләрнең берсе. Нәкъ менә сез - укытучылар , тәрбиячеләр, балаларда мөстәкыйльлек, жаваплылык, илебезнең матур киләчәге өчен иҗади хезмәт итуче шәхесләр тәрбиялисез. Сезнең фидакарь хезмәтегез, югары һөнәри осталылыгыз, сабыр һәм ярдәмчел булуыгыз өчен тирән ихтирамыбызны белдерәбез.**

**1аб. Хөрмәтле укытучыларыбыз, ә хәзер рөхсәт итегез, укытучылар көненә багышланган концерт - программабызны башлап җибәрергә.**

**2 аб. Тәүге тапкыр хәреф танырга, язарга, ә соңыннан укырга, санарга өйрәнү – беркемнең дә күңеленнән җуелмыйдыр мөгаен. Ә боларны өйрәтүче, белем дөньясына алып керүче башлангыч сыйныф укытучыларыбыз!Сезне бәйрәмегез белән котлап, рәхмәтебезне белдерәбез. Сезнең хөрмәткә җыр:..........башкаруында «Иң гүзәл кеше икәнсез»**

**Хөрмәтле, Гөлшат Мотаровна! Бәйрәм белән сезне. Тормышыгызда гел шатлыклар юлдаш булсын, гаиләгә иминлеге, саулык, эшегездә зур уңышлар теләп калабыз.**

**2аб. Гөлшат Мохтаровна –эшне оештыручы, балаларны яратучы педагог. Үзе белгәнне балаларга тапшырырга омтыла. Без укып белем алып кына түгел, эш эшли белергә, төрле эш кораларын танып белергә дә өйрәнеп чыгабыз. Егетләр хезмәт дәресләрендә бик күп төрле эшкә өйрәнәләр. Әйе, без аны хөрмәт итәбез, яратабыз. Ул балалар күңелен аңлый белә. Укытучыбызны бәйрәм белән тәбрик итәбез. Сәхнәдә .............Бию.**

**1 аб. Без кая гына барсак та, кайда гына йөрсәк тә, безгә иң кирәкле тел - рус теле. Русча белмәсән - беркем белән дә киңәшеп тә, сөйләшеп тә булмый. Әмма без тырыш укытучыларыбыз барында беркайда да югалып калмабыз. Хөрмәтле рус теле укытучыларыбыз! Сезгә рәхмәтебезне белдерәбез. Каршы алыгыз,сәхнәдә үзенең моңлы җырлары белән ........**

**2аб.......... Күп еллар буена мәктәптә биология һәм химия-фәннәрен укыта. ........ тынгысыз, тырыш педагог. Үз эшенең остасы. Эшләгән эшләренең нәтиҗәләре дә күренә. Район, Республика күләмендә оештырылган чараларда катнашып грамота, дипломнарына ия булды. Безгә төпле белем биреп, төрле олимпиада һәм чараларда катнашып, алдынгы урыннар алырга, ярдәм иткәне өчен аңа зур рәхмәтебезне белдерәбез. Һәм сезне бәйрәм белән котлыйбыз.**

**2аб. -Хөрмәтле укытучылар, укучылар! Дәрестә озак утырып арыгач, без нишлибез? Дөрес, физминутка ясыйбыз, ял итеп алабыз. Әйдәгез, без дә укытучылар белән уеннар уйнап алыйк.**

**Шушы уен өчен 3 укытучыбызны мәйданга чакырабыз.**

**(Укытучылар чыгып, тезелеп баскач кына)**

**- 1 уен: “Шигъри мизгел” дип атала. Уенның шарты мондый: Киселгән сүзләрдән шигырь җыярга, кем беренче булып шигырьне төзи һәм аны укып күрсәтә , шул җиңүче.**

**- ( Уенга нәтиҗә ясала, алкышлар белән җиңүче тәбрикләнә )**

**Физкультура дәресендә төрле спорт уеннарын без рәхәтләнеп уйныйбыз. Физкультура дәресе күп балаларның яраткан дәресе. Укытучы абыйларыбыз, сезне бәйрәм белән тәбрик итәбез. Сәламәтлек, эшегездә зур уңышлар телибез. Ә хәзер сәхнәбез түренә ..... чакырабыз.**

**Физика фәне сезгә бик кирәк,- ди укытучыларыбыз. Әйе, безне математика, физика фәннәре серенә төшендерүче, катлаулы мәсьәләләр чишәргә, олимпиадаларда җиңеп кайтуда безнең математика, физика укытучыларыбыз ........ өйрәтә. Рәхмәт сезгә хөрмәтле укытучыларыбыз. Сезне профессиональ бәйрәмегез белән тәбрикләп җыр башкара.**

**Сүзем ....... кызы турында.**

**1аб. Чит телне белү балаларга бик кирәк. ....... балаларга бу телне өйрәтүдә зур көч куя. Аларга эшендә яңа үрләр, гаиләдә бәхете теләп калабыз.**

**2аб Хөрмәтле татар теле һәм әдәбияты укытучылары ........ ,Сезне чын күңелебездән укытучылар көне белән котлыйбыз.Сезгә исәнлек, саулык,тыныч гомер , дөнья бәхете телибез.**

**Сезнең хөрмәткә җырлый -.......**

**2 аб Шулай ук география, рәсем, җыр фәннәрен укытучылары, бәйрәм белән котлыйбыз. Сез кече күңелле булуыгыз, сабыр, чыдамлылыгыз белән коллективның да, укучыларның да мәхәббәтен яуладыгыз. Тормышыгызда гел уңышлар туып торсын, исәнлек-саулык, эшегездә зур уңышлар теләп калабыз.**

**1аб.Кызлар хезмәт дәресендә төрле бүләкләр ясарга, чигәргә, бәйләргә өйрәнәләр. Мәктәптән кул һөнәрләренә,кул эшләренә, аш-суга оста булып чыгарга телиләр.**

**2аб. Бу эшләрне безгә өйрәтә укытучыларыбыз ..........!. Аларга зур рәхмәт әйтәсебез килә.**

**Оста, таләпчән, тәртип яратучы, шул ук вакытта кеше хәленә керә белүче, ярдәмчел тарих фәнен укытучыларыбыз сезне бәйрәм белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Сезгә исәнлек саулык, озын гомер, җан тынычлыгы теләп калабыз.Сезнең хөрмәткә.........җырлый.**

**Күптән түгел генә лаеклы ялга чыккан хөрмәтле укытучыларыбыз .........Без сезне һәрчак мәктәп бинасында күрергә шатбыз. Сезгә исәнлек - саулык, озын гомер,бәхетле киләчәк телибез. Сезне бәйрәмегез белән тәбрик итәбез.Сезнең хөрмәткә «Укытучыма»шигырен ...........укый.**

**1аб. Мәктәбебез якты, күңелле. Безнең өчен һәрнәрсә бар монда. Китапханә – балаларның яраткан бүлмәсе. Нинди генә китап юк бездә. Рәхәтләнеп укы гына. Китапханәчебез Айгөл апа ачык йөз белән каршы алып, ягымлы гына сөйләшеп, теләгән китабыбызны сайларга булыша. Рәхмәт сезгә. Бәйрәм белән котлыйбыз, сезгә озын гомер, саулык теләп калабыз.**

**2 аб. Мәктәп – бәхет йорты. Укучылар мәктәпнең кадерен белеп белем алырга тиеш.Тамагыбыз тук, өстебез бөтен. Без һәр көн кайнар чәй, кайнар аш белән тукланабыз, тагын ни кирәк безгә, әлбәттә мәктәпне яратырга, теләп йөрергә генә кала. Без бүген бәйрәм уңаеннан пешекче апаларыбызны да бәйрәм белән тәбрик итәсебез килә. Рәхмәт сезгә, тәмле ашларыгыз, якты йөзләрегез өчен! Сезне өчен скетч. 9 класс укучылары чыгышы.**

**1 аб. Мәктәбебез ишек төбеннән ук ялт итеп тора. Ә бу техник эшче апаларыбыз эше бит. Чиста мәктәптә укып йөрүе рәхәт безгә. Чисталык, пөхтәлек безнең сәламәтлегебезгә иң кирәкле нәрсә. Техничка апаларыбызга хезмәтләрендә уңышлар теләп калабыз. Бәйрәм белән сезне!**

**2 аб. Хөрмәтле укытучылар!Гасыр белән бергә атлап барырдай, заманга лаеклы алмаш тәрбияләүдә сез искиткеч җаваплы, олы эш алып барасыз.Тынгысыз хэм катлаулы, әмма изге һәм абруйлы хезмәтегездә уңышлар гына юлдаш булсын.**

**Үзегезнең тырышлык нәтиҗәсен укучыларыгызның өченче меңьеллыкның тулы хуҗалары булып, төрле өлкәләрдә уңышлы хезмәт куюларын күреп горурланырга насыйп булсын.**



Игътибар!!!




Яр Чаллы дәүләт педагогия университетының математика һәм информатика факультеты деканы Краснова Е.Л. чыгарылыш психологик-педагогик сыйныф укучылары белән очрашты. Елена Леонидовна укучыларны университетка керү һәм уку шартлары белән таныштырды. Очрашу диалог формасында узды..



21 нче сентябрь көнне ата-аналар укуы узды. Хәзерге заман мәктәбендә тәрбия мәсьәләсе елдан-ел катлаулана, яңа тәрбияви алымнар таләп итә. Тәрбия беренче чиратта гаиләдән башлана, ә мәктәп гаиләдә салынган тәрбия орлыкларын үстерүче , җәмгыятькә яраклашкан хәзерге заман шәхесен тәрбияләүче дә. Шушы темага якын килеп мәктәбебез әти-әниләре өчен җыелыш үткәрелде.



Иртәнге гимнастика-көн дәвамында энергия һәм уңай кәеф бирә торган күнегүләр комплексы. Мәктәп укучылары өчен иртәнге зарядка юкка гына уйлап чыгарылмаган. Ул уянырга, дулкынланырга ярдәм итә, организмның тонусын күтәрә, организмда кан әйләнеше процессын яхшырта, матдәләр алмашын нормальләштерә, токсиннар чыгаруга ярдәм итә, шатлык гормоны (эндорфин) җитештерүне активлаштыра..

**Яраткан укытучыма хат**

Бу сүзләрне йөрәгемә иң якын, иң кадерле булган кешеләремнең берсе - яраткан укытучым һәм сыйныф җитәкчемә багышлыйм.Күңел дәфтәрен актарып утырам. Әллә кайларда калган мәктәп еллары бер-бер артлы күз алдыма килеп баса. Әле башлангыч мәктәпне тәмамлап кына киләбез. Безнең күңелләрдә тик бер сорау: киләчәктә сыйныф җитәкчебез кем булыр? Зур кызыксыну һәм түземсезлек белән укытучы апабызны көтә башладык. Ниһаять, Ул килде... Сыйныф бүлмәсе әйтерсең кояш нурлары белән тулды. Укытучы өстәле янына барып басты да безнең белән таныште һәм үзе артыннан җитәкләп, белем дөньясына алып китте. Шушы бер күрүдә үз иткән, якын күргән, яраткан кешем - минем укытучым һәм сыйныф җитәкчем – Гайнетдинова Гөлназ Фәнис кызы булды.Беренче көннән башлап, укытучы апабыз безне - 14 укучыны үз канаты астына алып, җиде ел гомерен безне укытуга һәм тәрбияләүгә багышлады. Ниндидер могҗизалар көткән күңелләргә ачкыч таба белде. Ул һәрвакыт ягымлы итеп елмая, шул ук вакытта таләпчән булуын һәм кырыслыгын да күрсәтергә өлгерә иде. Без аны беренче мизгелдән үк аңларга өйрәндек. Ул һәр яктан да безгә үрнәк булды. Аның үз-үзен тотышына, матур итеп сөйләвенә, искиткеч зәвыклы итеп киенүенә, тәз итеп атлап йөрүенә сокланганнарым бүген дә хәтердә.Гөлназ апа безгә карата киң күңелле, гадел, искиткеч сабыр булды. Ул безнең белән бергә шатланды да, көенде дә. Көнне төнгә ялгап, безнең язмыш өчен борчылып яшәде, намуслы, кешеләргә карата шәфкатьле, мәрхәмәтле булырга өйрәтте. Һәрберебездә белем алуга аңлы караш, үз көченә ышаныч уята алды. Дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларга әзерләнгәндә дә һәрберебезнең табигать тарафыннан бирелгән сәләтен ачарга, үстерергә тырышты, һәркайсыбызны шәхес итеп күрә белде. Биергә, җырларга, сәхнәләрдә чыгыш ясарга өйрәткәндә без аның шулкадәр күп белүенә гаҗәпләнә идек. Төрле бәйгеләрдә, ярышларда, бәйрәмнәрдә сыйныфыбыз һәрчак алдынгылар рәтендә булды, чөнки безнең Гөлназ апабыз тынгысыз йөрәкле, уңган-булган, тырыш, заманча итеп әйтсәк, компетентлы педагог иде.Татар теле һәм әдәбияты укытучысы һәм сыйныф җитәкчесе булып эшләү дәверендә Гөлназ Фәнисовна безгә белем һәм тәрбия генә түгел, үзенең йөрәк җылысын да бирде, тормышны танырга, авырлыкларны җиңәргә, ялгышларны вакытында төзәтергә өйрәтте.Шулай сизелми генә мәктәп еллары да үтеп китте. Соңгы кыңгырау бәйрәмнәрендә, Чыгарылыш кичәләрендә Гөлназ апаның күңелендәге сагыш та, безне үз балаларыдай якын күреп, өзелеп яратуы да күз яшьләре булып түгелделәр., чөнки без - Гөлназ апаның Мөслим урта мәктәбендәге иң беренче чыгарылыш сыйныф укучылары. Укытучыбызның барыбызны да тигез күреп яраткан йөрәге безгә бәхет, изге теләкләр теләп, олы тормыш юлына озатып калды. Ул вакытлар - бик күп айлар һәм еллар артта калган. Без - Гөлназ апаның укучылары, төрле якка таралышып, үзебезгә ошаган һөнәр ияләре булганга да ике дистәдән артык вакыт үткән. Әйе, еллар дәвамында кадерле апабыз безнең күңелләрдә үз һөнәренә карата олы мәхәббәт хисләре тәрбияләгән икән бит!

Яраткан укытучым бүген Мөслим авылында гомер итә. Без оештырган очрашуларга килә, хәлләребезне сораша, уңышларыбызга сөенә.Минем өчен ул - һаман да шул ук янып, балкып торган белемле укытучы, әнием урынына күреп яраткан сыйныф җитәкчесе.Җәй аеның соңгы көннәрендә хөрмәтле укытучым үзенең туган көнен билгеләп үтә. Мин аны бу шатлыклы бәйрәме белән чын күңелдән котлыйм.Кадерле укытучым, Гөлназ Фәнисовна! Йөрәгемдәге изге теләкләрем, күңелемне биләгән ярату һәм соклану хисләрем бүген Сезгә котлау булып барып ирешсеннәр иде. Җәй кояшы кебек, безнең күңелләрне җылыткан олы йөрәгегезгә беркайчан да кайгылар килеп кагылмасын, сыйныфыбызда һәр кешегә дә матур итеп карый белгән күзләрегез яшьләнмәсен, бөдрә чәчләрегезгә аклык кунмасын, ягымлы йөзегездән беркайчан да елмаю сүрелмәсен.Сез иң гүзәл дә, иң тыйнак та, сабыр да, иң күркәм дә... Рәхмәт Сезгә, хөрмәтле укытучым! Кайларда гына булсам да, Сез - минем кадерле укытучым булып, йөрәгем түрендә сакланырсыз.Киләчәк көннәрегездә исәнлек-саулык, шатлык-куанычлар, гаиләгездә тигезлек телим. Балаларыгыз, оныкларыгыз, якыннаргыз белән бәхетле мизгелләр кичереп, озак еллар безнең белән күрешеп яшәргә насыйп булсын Сезгә!

**2004 нче елгы чыгарылыш укучыгыз Имамиева Гөлфия**.



















# Укучыларыбыз иҗаты

**6”б”сыйныфы укучылары яза...**
**Укытучыма әйтер сүзем бар...**

**Габдрахманова Рания:**
Әлфия Ясәвиевна рус теленнән укыта. Миңа аның яхшы күңелле булуы, безне тәрбияләве, матур йөзләре, бик гадел, бик әйбәт аңлатуы ошый. Миңа аның килешмәгән ягы бар. Ул ял көннәргә өй эше бирә. Мин Әлфия Ясәвиевнага саулык, сәламәтлек, озын гомер, чирләмәвен, көнннәренең әйбәт үтүен телим. Мин сезне бик нык яратам!

**Абдукаева Регина:**
Минем яраткан укытучым Эльмира Проталионовна. Ул безгә математика фәненнән керә. Математика фәне миңа нык ошый. Ул нык әйбәт, аңлаешлы аңлата, мисаллар күрсәтә, шуңа мин математика фәнен әйбәт беләм. Математика-ул нык кирәк фән, ләкин яратмаган яклары да бар. Миңа ошамый ничек ул ярты дәрес биремнәрне аңлата, ә аннары контроль эш бирә. Эльмира Проталионовнага уңышлар, озын гомерле булсын, чирләмәсен, саулыклар телим.

**Минниярова Азалия:**
Минем ин яраткан укытучы Гөлназ Фанисовна.Ул татар теле дәресен укыта. Миңа ул укытучы ошый, чөнки ул гадел, әйбәт, темаларны аңлатып укыта. Мин аңа бәхет шатлык, яхшы гомер һәм иң изге теләкләр телим!!!

**Сәлахова Камила:**
Минем бер укытучым бар. Анын исеме- Йолдыз Рәисовна.Ул тарих һәм җәмгыять фәннәрен укыта.Мин аны бик ошатам.Чөнки ул бик әйбәт аңлата , ул бик чибәр, гел мисаллар китерә, ул бик яхшы. Миңа аның дәфтәрдән укысаң, дүртле куйганы ошамый.Мин Йолдыз Рәисовнага шулай ук матур , чибәр, яхшы булып калуын телим. Бу мәктәптә тагын да күп еллар укытырга язсын. Мин бик яратам Йолдыз Рәисовнаны!

**Гильмутянова Эльвира**
Эльмира Проталионовна- математик укытучы. Гел булыша үзебезгә, аңлатырга тырыша, аңламасаң булыша. Бер кеше де аңламыйча калмый. Кемгә салкын, кемгә кызу, кем аңламый, кем аңлый, барыбер булыша. Мин аның белән бөтен яктан да килешәм. Мин аның исән- сау гына эшләвен телим, без аны нык яратабыз.

**Шакирова Самира:**
Зилә Вилевна инглиз теле фәнен укыта. Ул тыныч, матур, әйбәтләп аңлата, кызык дәресләр үткәрә.Миңа аның ошамый торган ягы: ул инглизчә күп сөйләшә һәм мин кайбер сүзләрен аңламыйм.Зиля Вилевна, мин сезгә телим бәхет, шатлык, исәнлек- саулык, чирләмәгез,озак-озак еллар эшләгез, балаларыгыз тыныч, тәртипле булсын, сез нык әйбәт укытучы, без сезне яратабыз.

**Галеева Камилә:**
Минем яраткан укытучы- Әлфия Ясәвиевна, ул рус теле һәм рус әдәбияты фәннәрен укыта.Мин аны бик нык ошатам, чөнки ул бик дөрес, аңлаешлы, бөтен кешегә аңларлык итеп аңлата. Миңа аның бөтен җире ошый, ләкин ул чагыштыра безне 6в һәм 6г малайлары белән, шул ягы белән генә мин килешмим. Мин Әлфия Ясәвиевнага иң изге теләкләр телим: бәхет, шатлык, сәләмәтлек, озын гомер, киләсе елга да безне укытсын, шундый гүзәл, җылы күңелле, матур йөзле, тәрбияле булып калсын. Мин аны бик нык яратам.

**АглееваАзалия:**
Минем яраткан укытучым- Энже Ирековна, ул безгә музыка фәненнән керә. Мин аны ошатам әйбәтлеге, гаделлеге, матурлыгы өчен! Миңа Энже Ирековнада җырлар ятларга биргәне ошамый. Мин Энже Ирековнага әйбәт чирләмәсен, теләкләр телисе килә: матур, әйбәт, озын гомерле булсын һәм шундый әйбәт булып калсын!!!

**ХәйертдиноваМәликә** :
Әлфия Ясәвиевна- рус теле укытучысы, миңа нык ошый, ул әйбәт, аңлата белә, өй эшләрен аңлатып бирә.Миңа аның күп өй эше бирү ошамый.Мин үземнең укытучыма шатлык, бәхет, озын гомер, иң изгетеләкләртелим!

**ХафизоваАдилә** :
Гүзәл Хамзовна- инглиз теле укытучысы. Мин аны яратам, чөнки ул нык яхшы, чибәр, матур, яхшы күңелле. Мин аңа яхшы теләкләр, елмаеп торуын гына телим. Мин аңа тагын да шулай итеп эшләргә язсын дип телим һәм мин Гүзәл Хамзовнаны бик нык яратам.

**СәхәбетдиноваМилана:**
Минем яраткан укытучым- Эльмира Проталионовна. Ул бездә математика алып бара. Ул һәрвакыт барысын да аңлый. Ул әгәр ул аның фәнен начар белсә, укучысына ярдәм итә. Әгәр дә мин, мәсәлән, теманы аңламасам, ул аны тагын бер тапкыр аңлата. Минемчә, аның бернинди дә тискәре яклары юк, ул бик игелекле һәм яхшы укытучы. Мин аңа шундый ук шат күңелле һәм игелекле булып калуынтеләридем.

**МөэминоваАлзилә:**
Минем яраткан укытучым Гөлназ Расиховна. Ул безгә рәсем фәненнән укыта. Мин аны ошатам, чөнки ул әйбәт аңлата, гадел һәм бик нык әйбәт.Миңа аның дәресләре бик ошый. Мин Гөлназ апага иң изге теләкләр телим: сәламәтлек, бәхет, шатлык һәм озын гомерле булсын.

**Фәттахова Эльвира:**
Минем яраткан укытучым-география укытучысы Ринат Хазеев Рифович.Миңа аның яхшы, өй эшен бик әз бирүе, аңлатуы ошый. Мин Ринат Рифовичка иң яхшысын телим! Укучыларыгыз сезне яратсын, ә сез аларны! Озак һәм бәхетле яшәгез!!!

**Гибадуллина Әминә:**
Гүзәл Хамзовна- ул инглиз теле укытучысы. Мин аны бик яратам, чөнки ул иң яхшы инглиз теле укытучы. Мәктәптә өй эшен әз бирә, нык чибәр. Гүзәл Хамзовнага мин аңа озын гомер һәм яхшы гомер, балаларяратуынтелим.

**ӘминәМөхәмәтдинова:**
Һәр укучының да үзенең генә яраткан, хөрмәт иткән укытучысы була. Минем дә яраткан укытучым бар. Ул тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы- Йолдыз Рәисовна. Ул дәрестә бик әйбәт аңлата, теманы балалар яхшы белсеннәр өчен үз көчен кызганмый. Аның өй эшен аз бирүе миңа, бигрәк тә ошый. Ләкин Йолдыз Рәисовна дәрестә күбрәк яздырта. Минем укытучыма озын гомер, ныклы сәламәтлек, балалар белән эшләү өчен сабырлык, көч һәм эшендә тагын да зур уңышларга ирешүен һәм безне шулай яхшы итеп укытуынтелим.

«Тукай ялкыны”, октябрь, 2023 нче ел, Г.Тукай ис.Мөслим урта мәктәбе укучылары газетасы Баш мөхәррир: Гайнетдинова Г.Ф.
Корреспондентлар Нуреева Алия, Жаббарова Диана
Дизайнер Әсәдуллина Айзилә. Компьютерда җыючы: Галеева Камилә, Миргалимова Эльвина .Гамәлгә куючы: Г.Тукай ис.Мөслим урта мәктәбе укучылар иҗат үзәге Адрес: Мөслим, Тукай 21 Электрон адрес: s2.mus@mail.tatar.ru 100 экземпляр.